**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «02» декабреннән № 341

**«2016 елга Яңа Чишмә муниципаль районының Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләренә норматив финанслауны кертү турында» карары һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы уставы нигезендә карар бирәм:

1. 2016 елга түбәндәгеләрне расларга:

Яңа Чишмә муниципаль районының сәнгати-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Яңа Чишмә муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Расланган
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «02» декабрендәге
341номерлы карары белән

**Яңа Чишмә муниципаль районы сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**

# НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнары (1 укучыга бер елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | жиде-еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 40 815 | 44 972 | 65 325 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 23 957 | | 19 788 | 50 778 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 46 098 | 37 414 | 147 805 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 19 394 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 41 869 | 38 994 | 69 409 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 68 000 | | 60 518 | | 107 040 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 35 414 | | 30 898 | 29 926 | 50 270 |